КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 24 декабрь г.Казань № 1183

Татарстан Республикасында инновация һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендәге чараларны тормышка ашыру буенча коммерциягә карамаган оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасында инновация һәм инвестиция эшчәнлеге чараларын тормышка ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасында инновация һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендәге чараларны тормышка ашыру буенча коммерциягә карамаган оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.
2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 24 декабрь, 1183 нчы
карары белән расланды

Татарстан Республикасында инновация һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендәге чараларны тормышка ашыру буенча коммерциягә карамаган оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм Татарстан Республикасында инновация һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендәге чараларны тормышка ашыру буенча коммерциягә карамаган оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидия) бирү механизмын, максатларын һәм шартларын билгели.

2. Субсидияләр бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан бирелә; тиешле финанс елына субсидияләр бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитлары аңа бюджет акчасын алучы буларак Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән була.

3. Субсидияләр субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзергә планлаштырыла торган айның 1енә түбәндәге таләпләргә туры килә торган коммерциягә карамаган оешмаларга бирелә:

эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашыру;

коммерциягә карамаган оешманы гамәлгә куючыларның берсе Татарстан Республикасы һәм (яки) гамәлгә куючысы бары тик Татарстан Республикасы гына булган юридик зат булу;

Татарстан Республикасында инновация һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендәге чараларны тормышка ашыру буенча тәҗрибәсе булу;

устав эшчәнлеге инновация һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендәге чараларны тормышка ашыруга юнәлдерелү;

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәләре булмау;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмау;

үзгәртеп оештыру, бетерелү процессында булмау, аңа карата банкротлык процедурасы башланмау, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмау;

бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан

Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмау.

4. Коммерциягә карамаган оешмаларның финанслар белән тәэмин итү өчен субсидияләр бирелә торган чыгымнар юнәлешләре – ул инновация һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендә түбәндәге чараларны тормышка ашыруга бәйле чыгымнар:

форумнар, күргәзмәләр, конгресслар, конференцияләр, съездлар, бизнес-миссияләр, семинарлар, стратегик сессияләр, түгәрәк өстәлләр утырышларын, шулай ук Татарстан Республикасында инвестицион климатны яхшыртуга, инвестицияләр җәлеп итүгә һәм Татарстан Республикасының халыкара элемтәләрен үстерүгә, эшмәкәрлек эшчәнлеген популярлаштыруга юнәлдерелгән комиссияләр утырышларын оештыру, үткәрү һәм аларда катнашу;

коммерциягә карамаган оешманың сайтын һәм инновация һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендәге чаралар мониторингының мәгълүмати системасын булдыру, үстерү һәм эксплуатацияләү;

эксперт һәм консультация хезмәтләре күрсәтү;

белем бирү чараларын оештыру һәм үткәрү;

Россия Федерациясенең Сәнәгатьне үстерү фонды тарафыннан сайлап алынган юридик затларга максатчан заемнар бирү юлы белән проектларны инвестицияләү;

элемтә хезмәтләре һәм почта чыгымнары өчен түләү;

автотранспортка хезмәт күрсәтү;

командировка чыгымнары;

мөлкәтне карап тоту буенча эшләр башкару һәм хезмәт күрсәтүләр, бина урыннарын һәм җиһазларны арендалау;

граждан-хокукый характердагы шартнамәләр буенча җәлеп ителгән белгечләрнең хезмәте өчен түләү;

массакүләм мәгълүмат чараларында һәм интернет-ресурсларда коммерциягә карамаган оешманың эшчәнлеген яктырту;

чыгым материаллары өчен түләү;

электрон мәгълүматлар базаларына һәм программа продуктларына хезмәт күрсәтү;

аудит;

документларны архивка ярашлы рәвештә эшкәртү буенча хезмәт күрсәтүләр;

вакытлы басмаларга язылу.

Бу пункт белән күздә тотылган чыгымнар тәңгәл (бер үк төрле) товарларның, эшләр башкаруның, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматны, шул исәптән җитештерүче оешмаларның бәяләре турындагы, дәүләт статистикасы органнарындагы, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларындагы һәм махсус әдәбияттагы (җитештерүчеләрнең һәм тәэмин итүчеләрнең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтларын кертеп) бәяләр дәрәҗәсе турындагы мәгълүматны анализлаудан гыйбарәт базар бәяләрен чагыштыру (базарны анализлау) ысулы белән билгеләнә.

5. Субсидия алу өчен коммерциягә карамаган оешмалар Министрлыкка түбәндәге документларны үз эченә алган заявка тапшыра:

бу Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтадагы форма буенча субсидия бирүгә гариза;

гамәлгә кую документларының күчермәләре;

салым органының килешү төзергә планлаштырыла торган айның 1енә Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычлары булмауны раслый торган белешмә кәгазе;

Татарстан Республикасында инновация һәм инвестиция эшчәнлеген үстерүгә юнәлдерелгән чараларны үткәрүне күздә тота торган өчьеллык чорга эшчәнлек планы;

бу Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән юнәлешләр буенча чыгымнарның өчьеллык чорга финанс-икътисадый нигезләмәсе теркәлгән сметасы.

6. Документларны коммерциягә карамаган оешмалар кәгазь һәм электрон чыганакларда тапшыра.

Кәгазь чыганакта тапшырылган барлык документлар төгәл итеп басылган булырга тиеш. Чистартулар һәм төзәтүләр (коммерциягә карамаган оешманың мөһере (мөһере булганда) һәм вәкаләтле вәкиленең имзасы белән расланган төзәтмәләрдән тыш) рөхсәт ителми. Кәгазь чыганакта тапшырылган заявканың барлык битләре нумерланган булырга тиеш. Кәгазь чыганакта тапшырылган заявка тегелгән һәм, заявканың икенче ягында гомуми битләр санын күрсәтеп, коммерциягә карамаган оешманың вәкаләтле заты имзасы һәм мөһере (мөһере булганда) белән расланган булырга тиеш.

Коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан бу Тәртипнең 5 нче пунктындагы дүртенче абзацы белән күздә тотылган документ тапшырылмаган очракта, Министрлык әлеге документны вәкаләтле дәүләт хакимияте органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

7. Заявкаларны кабул итү Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Заявкаларны кабул итү чоры, заявкаларны сайлап алу буенча комиссия (алга таба – комиссия) утырышының көне һәм вакыты Министрлыкның карары белән билгеләнә. Заявкаларны кабул итү чоры, комиссия утырышының көне һәм вакыты турындагы мәгълүмат конкурс заявкаларын кабул итә башлаган көнгә кадәр эш көннәрендә исәпләнә торган бер көн эчендә Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында басылып чыга.

8. Заявка Министрлык тарафыннан заявкаларны теркәү журналында (алга таба – журнал) ул кергән көнне теркәлә.

Әгәр дә сайлап алуда катнашу өчен бер заявка да бирелмәгән булса, сайлап алу үткәрелмәгән дип санала.

9. Заявкалар Министрлык тарафыннан бу Тәртип таләпләренә туры килү-килмәүгә журналда теркәлгән көннән ике эш көне эчендә тикшерелә.

10. Сайлап алуны үткәрү комиссия тарафыннан гамәлгә ашырыла. Комиссия составы Министрлык тарафыннан раслана. Сайлап алу нәтиҗәләре белән шәхсән кызыксынган затлар (шул исәптән заявкалар тапшырган йә заявкалар тапшырган коммерциягә карамаган оешмалар штатында торган) йә сайлап алуда катнашучылар йогынты ясау мөмкинлеге булган затлар комиссия әгъзалары була алмый.

11. Комиссия утырышы, әгәр дә анда комиссия әгъзаларының кимендә яртысы катнашса, тулы хокуклы була.

12. Заявкаларны карап тикшергәндә комиссия түбәндәге критерийларга

таянып эш итә:

коммерциягә карамаган оешманың устав максатлары, бурычлары һәм эшчәнлек төрләре Татарстан Республикасында инновация һәм инвестиция эшчәнлеген үстерү мәсьәләләрен хәл итүгә юнәлдерелү;

коммерциягә карамаган оешма федераль законнар нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә субсидия алу хокукына сайлап алуны игълан итү көненә кадәр кимендә 10 ел элегрәк теркәлгән булу;

коммерциягә карамаган оешманың Татарстан Республикасында инновация һәм инвестиция эшчәнлеген үстерүгә юнәлдерелгән чаралар үткәрүне күздә тота торган өчьеллык чорга эшчәнлек планы булу.

Заявкалар һәр критерий буенча 5 баллы шкала (1дән 5кә кадәр) нигезендә Министрлык тарафыннан расланган формадагы тавыш бирү кәгазенә баллар кертү юлы белән бәяләнә.

Субсидия заявкасы иң күп балл җыйган коммерциягә карамаган оешмага бирелә. Баллар тигез булса, журнал буенча беренче булып заявка биргән коммерциягә карамаган оешма өстенлеккә ия була.

13. Конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре буенча комиссия сайлап алуның җиңүчесен билгеләү турында карар кабул итә.

14. Комиссия карары беркетмә белән рәсмиләштерелә, аны комиссия сәркатибе алып бара. Беркетмә комиссия утырышы үткәрелгән көнне комиссия рәисе тарафыннан раслана.

15. Беркетмә Министрлык тарафыннан аны раслаган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган бер көн эчендә Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

16. Конкурс комиссиясенең гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына карата коммерциягә карамаган оешма тарафыннан законнар белән билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

17. Министрлык:

беркетмә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырылган көннән бер көн эчендә субсидия бирү турында яки аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә;

субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган өч көн эчендә коммерциягә карамаган оешма белән субсидия бирү турында килешү төзи.

18. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

коммерциягә карамаган оешманың бу Тәртипнең 3 нче пункты белән билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

коммерциягә карамаган оешманың бу Тәртипнең 5 нче пунктындагы икенче, өченче, бишенче һәм алтынчы абзацларында күрсәтелгән документларны тапшырмавы (тулы күләмдә тапшырмавы);

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан тапшырылган документларның, алардагы мәгълүматларның бу Тәртип белән каралган таләпләргә һәм шартларга туры килмәве;

коммерциягә карамаган оешма тарафыннан тапшырылган мәгълүматның дөрес булмавы;

бюджет йөкләмәләре лимитларының булмавы.

Субсидия бирүдән баш тартылган очракта, Министрлык карар кабул иткән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган бер көн эчендә бу турыда коммерциягә карамаган оешмага хәбәрнамә җибәрә.

19. Татарстан Республикасында инновация һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендәге чараларны тормышка ашыру буенча коммерциягә карамаган оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә субсидияләр күләмен исәпләү түбәндәге формула буенча гамәлгә ашырыла:

$$С_{фо} = P_1 + P_2 + P_3 + ... + P_n ,$$

монда:

$С_{фо}$ – субсидия күләме;

$P_1$, $P_2$, $P_3$ ... $P_n$ – бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән һәм бу Тәртипнең 4 нче пунктындагы юнәлешләр буенча финанслар белән тәэмин ителергә тиеш булган чараларны тормышка ашыруга юнәлдерелгән чыгымнар.

20. Министрлык һәм коммерциягә карамаган оешма арасында Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән форма буенча төзелә торган килешү субсидия бирү өчен нигез була.

21. Килешүдә түбәндәгеләр күздә тотыла:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, аларның финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар юнәлешләре, аны Татарстан Республикасы бюджетыннан бирү шартлары һәм тәртибе;

субсидия бирү нәтиҗәләренең мәгънәләре;

субсидия күчерү вакытлары;

финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар турында хисап документлары һәм субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәләренә ирешү турында хисап документлары бирү вакытлары, формасы һәм тәртибе;

Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары тарафыннан субсидия алучының Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыруга хокук;

агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан хисап финанс елында субсидияләрнең файдаланылмый калган өлешен кире кайтару очраклары;

Министрлык субсидиянең калган өлешен куллануга ихтыяҗ булу турында карар кабул иткәндә, хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше финанслар белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тота торган шарт;

субсидия алучының Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыру өчен субсидия алучының һәм субсидияләр бирү турындагы килешү буенча йөкләмәләрне үтәү максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) булган затларның ризалыгы;

алынган субсидияләр исәбенә чит ил валютасын сатып алуны (югары технологияле чит ил җиһазларын, чималын һәм комплектлау әйберләрен сатып

алганда (кайтартканда) Россия Федерациясенең валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш) тыю;

бу Тәртип белән билгеләнгән шартлар бозылган очракта, килешүне өзү тәртибе;

субсидия алучы тарафыннан максатчан файдаланышын тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру тәртибе;

субсидия алучы тарафыннан бу Тәртип һәм төзелә торган килешү шартлары үтәлеше турындагы нигезләмә.

22. Татарстан Республикасында тиешле финанс елында инвестиция һәм инновация эшчәнлеге өлкәсендә килешү белән билгеләнгән тормышка ашырылган чаралар саны субсидия бирү нәтиҗәсе булып тора.

23. Килешү проекты субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган бер көн эчендә Министрлык тарафыннан имза кую өчен коммерциягә карамаган оешмага җибәрелә.

24. Килешүгә коммерциягә карамаган оешма ягыннан имза куелган килешүне алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган бер көн эчендә Министрлык тарафыннан имза куела.

25. Министрлык субсидияне килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган ике көн эчендә коммерциягә карамаган оешманың Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениесендә яки Россия Федерациясе территориясендә теркәлгән кредит оешмасында ачылган исәп-хисап счетына күчерә.

26. Коммерциягә карамаган оешма тапшырыла торган мәгълүматларның дөрес булмавы һәм субсидияне максатчан файдаланмау өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

27. Коммерциягә карамаган оешма, хисап елыннан соң килә торган елның 30 эш көненнән дә соңга калмыйча, бу Тәртипкә теркәлгән 2 нче кушымтада бирелгән форма буенча килешү белән билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында хисап кертә.

28. Субсидия Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына түбәндәге очракларда кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән, Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган шартлар бозылганда;

субсидия алучы тарафыннан субсидия алу өчен дөрес (тулы) булмаган мәгълүматлар һәм документлар тапшырылганда;

финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнар турындагы хисапны килешү белән билгеләнгән вакытта тапшырылмаганда;

субсидия чараларыннан максатчан файдаланылмаганда;

субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешелмәгәндә.

29. Килешү белән каралган очракларда, хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше, хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты керемен кире кайтарылырга тиеш (Министрлык тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп әлеге акчага ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгән

очраклардан тыш).

30. Субсидияне, бу Тәртипнең 28 һәм 29 нчы пунктларында күрсәтелгән субсидиянең калган өлешләрен кире кайтару вакытлары бозылган очракларда, Министрлык субсидияне, субсидиянең калган өлешләрен кире кайтару вакыты чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә Россия Федерациясе законнары нигезендә әлеге акчаны мәҗбүри тәртиптә түләттерү буенча чаралар күрә.

31. Министрлык һәм дәүләт финанс тикшерүе органнары бу Тәртип һәм килешү белән билгеләнгән субсидияләр бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәүне тикшерүне гамәлгә ашыра.

32. Субсидиядән максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасында инновация һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендәге чараларны тормышка ашыру буенча коммерциягә карамаган оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә 1 нче кушымта

Форма

Коммерциягә карамаган оешма тарафыннан
Татарстан Республикасында инновация һәм инвестиция эшчәнлеге
өлкәсендәге чараларны тормышка ашыру буенча коммерциягә карамаган
оешма чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә
Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр алуга
гариза

1. Гариза бирүче оешманың исеме: ______________________________________________
________________________________________________________________________________
2. Адресы: ______________ _______________________________________________________
(индексы) (юридик адресы)

_________________ _______________________ _______________________________________
(телефоны) (факсы) (e-mail)

3. Коммерциягә карамаган оешма җитәкчесенең фамилиясе, исеме, атасының исеме:
________________________________________________________________________________
телефоны: ______________________________________________________________________
4. Коммерциягә карамаган оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек төрләре турында мәгълүмат: ___________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
5. Элемтәгә керү өчен мәгълүмат, җаваплы затларның фамилиясе, исеме, атасының исеме: _________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
________________________________________________________________________________
6. Субсидия күчерү өчен реквизитлар:
ИНН: ___________________________________________________________________________
КПП: ___________________________________________________________________________
Адресы: ________________________________________________________________________
Исәп-хисап счеты: ______________________________________________________________
Банк: __________________________________________________________________________
БИК: ___________________________________________________________________________
Корреспондент счеты: ___________________________________________________________
Телефоны: ______________________________________________________________________

Гаризада бирелгән мәгълүматның дөреслегенә гарантия бирәбез һәм бездән, дәүләт һәм муниципаль хакимиятнең вәкаләтле органнарыннан әлеге белешмәләрне тәгаенли торган мәгълүматны соратып алу хокукын раслыйбыз.

Кушымта:

1. Чыгымнар сметасы (җитәкче тарафыннан расланган) ____________________.
(чара исеме)

2. Татарстан Республикасында инновация һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендәге чараларны тормышка ашыру буенча коммерциягә карамаган оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибендә (алга таба – Тәртип) күрсәтелгән чыгымнар юнәлешләре буенча документлар күчермәләре _________________________ ____________________________________________________________________________.

3. Коммерциягә карамаган оешманың гамәлгә кую документлары, шулай ук аларга карата булган барлык үзгәрешләр турындагы документлар күчермәләре.

4. Субсидия алучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры тарафыннан имзаланган түбәндәгеләр турындагы белешмә кәгазе:

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмау;

үзгәртеп оештыру, бетерелү процессында булмау, аңа карата банкротлык процедурасы башланмау, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмау (әгәр дә мондый таләпләр хокукый акт белән күздә тотылмаса);

бу Тәртипнең 1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмау.

5. Башка документлар.

Җитәкчесе ____________________________ __________________________________
(имзасы) (Ф.Ис.Ат.ис.)

Баш бухгалтеры __________________________ _________________________________
(имзасы) (Ф.Ис.Ат.ис.)

М.У. (булганда)
20__ ел, «__» __________

Минем шәхси мәгълүматларны «Шәхси мәгълүматлар турында» 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә эшкәртүгә ризалыгымны бирәм.

Җитәкчесе ____________________________ ____________________________
(имзасы) (Ф.Ис.Ат.ис.)

Баш бухгалтеры __________________________ _________________________________
(имзасы) (Ф.Ис.Ат.ис.)

Татарстан Республикасында инновация һәм инвестиция эшчәнлеге өлкәсендәге чараларны тормышка ашыру буенча коммерциягә карамаган оешмалар чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

20__ елның ________________ хәленә карата
субсидияләр бирү нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында
хисап

Коммерциягә карамаган оешманың исеме: _______________________________

Дәвамлылыгы: ________________________________________________________

| Т/с | Нәтиҗә исеме | Гомумроссия үлчәү берәмлекләре классификаторы буенча үлчәү берәмлеге | | Нәтиҗәнең план буенча әһәмияте | Хисап көне хәленә карата буенча нәтиҗәнең ирешелгән мәгънәсе | Планны үтәү проценты | Тайпылу сәбәбе |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | исеме | коды | | | | |
| 1 | 2 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| 1. | | | | | | | |
| … | | | | | | | |

Коммерциягә карамаган
оешма җитәкчесе
(вәкаләтле зат ) _________________ ___________ _______________________
(вазыйфасы) (имзасы) (имзасын таркатып язу)

Үтәүчесе _______________ ___________________________ __________________
(вазыйфасы) (Ф.И.Ат.ис.) (телефоны)

20__ ел, «____» _____________

___________________________________